# Рамазан ае

## شهر رمضان

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

Sarhaan.com
Mahadsunnah.com

136 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр итеалә:

بُنِيَ الإِسْلَامُ عَلَى خَمْسٍ: شَهَادَةِ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ، وَ أَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ، وَ إِقَامِ الصَّلَاةِ، وَ إِيتَاءِ الزَّكَاةِ، وَ صَوْمِ رَمَضَانَ، وَ حَجِّ البَيْتِ

«Ислам биш баганага нигезләнә: Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк һәм Мөхәммәд – Аллаһның илчесе дип шәһәдәт китерү, намазны торгызу (уку), зәкәт түләү, Рамазан аенда ураза тоту, һәм Аллаһ йортына хаҗ кылу».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 2840.

222 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр итеалә:

الصَّلَوَاتُ الخَمْسُ، وَالجُمْعَةُ إِلَىٰ الجُمْعَةِ، وَرَمَضَانُ إِلَىٰ رَمَضَانَ مُكَفِّرَاتٌ لِمَا بَيْنَهُنَّ إِذَا اجْتُنِبَتِ الكَبَائِرُ

«Биш вакыт намаз, бер җомга намазыннан ( җомга намазын уку) икенче җомга намазына кадәр, бер Рамаданнан ( Рамаданда ураза тоту) икенче Рамаданга кадәр - бу гамәлләрнең һәммәсе дә, әгәр кеше зур гөнаһлардан читләшсә, алар арасындагы гөнаһлардан гафу ителү сәбәбе (йолу) булып тора».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 3875.

382 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр ителә:

لَيْسَ الصِّيَامُ مِنَ الأَكْلِ وَالشُّرْبِ، إِنَّمَا الصِّيَامُ مِنَ اللَّغْوِ وَالرَّفْثِ فَإِنْ سَابَّكَ أَحَدٌ، أَوْ جَهِلَ عَلَيْكَ فَقُلْ: إِنِّي صَائِمٌ إِنِّي صَائِمٌ

«Ураза – ул ашау-эчүдән генә тыелып тору түгел, ә шулай ук буш (юк–бар) һәм начар сүзләрдән дә тыелу булып тора. Әгәр кемдер сине сүгә башласа яки сиңа карата наданлыгын күрсәтә башласа, (ул чагында) син аңа: «Мин ураза тотам, мин ураза тотам», - дип әйт».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 5376.

401 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр ителә:

مَنْ أَكَلَ، أَوْ شَرِبَ نَاسِيًا فَلَا يُفْطِرْ، فَإِنَّمَا هُوَ رِزْقٌ رَزَقَهُ اللَّهُ

«Ураза вакытында онытылып ашаган яки эчкән кешенең уразасы бозылмый, хакыйкатьтә, ул Аллаһ биргән ризык, Аллаһ аны ризыкландырды».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 6082.

559 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр итеә:

قَالَ اللّٰهُ تَعَالَىٰ: كُلُّ عَمَلِ ابْنِ آدَمَ لَهُ إِلَّا الصِّيَامُ فَإِنَّهُ لِي وَأَنَا أَحْزِي بِهِ، وَالصَّيَامُ جُنَّةٌ؛ وَإِذَا كَانَ يَوْمُ صَوْمِ أَحَدِكُمْ فَلَا يَرْفُثْ، وَلَا يَصْخَبْ، وَإِنْ سَابَّهُ أَحَدٌ أَوْ قَاتَلَهُ فَلْيَقُلْ: إِنِّي امْرُؤٌ صَائِمٌ، وَالذي نَفْسُ مُحَمَّدٍ بِيَدِهِ لَخَلُوفُ فَمِ الصَّائِمِ عِنْدَ اللّٰهِ أَطْيَبُ مِنْ رِيحِ المِسْكِ، وَلِلصَّائِمِ فَرْحَتَانِ يَفْرَحُهُمَا: إِذَا أَفْطَرَ فَرِحَ بِفِطْرِهِ، وَإِذَا لَقِيَ رَبَّهُ فَرِحَ بِصَوْمِهِ

«Бөек Аллаһ әйтте: «Адәм баласының уразадан кала барлык гамәлләре аның үзенә, ул( ураза) Минем өчен һәм Мин аның өчен әҗер-савап бирермен; ураза гөнаһлардан калкан булып тора; әгәр берәрегез ураза тотса, начар сүзләр әйтмәсен, ачуланмасын һәм кычкырмасын; әгәр аның белән берәрсе сугыша башласа яки аны сүксә, ул: «Чынлыкта,мин ураза тотам!»,- дип әйтсен. Һәм  Мөхәммәднең җанына хуҗа булган Аллаһ белән ант итәм – ураза тотучының авызыннан чыккан ис Аллаһ өчен мускус исеннән ямьлерәк. Ураза тотучы ике нәрсәгә сөенә: ураза тотып авыз ачканы өчен һәм үз Раббысы белән очрашкач уразасы өчен».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 4328.

576 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр ителә:

قَالَ اللّٰهُ تَعَالَىٰ: كُلُّ عَمَلِ ابْنِ آدَمَ لَهُ إِلَّا الصِّيَامُ فَإِنَّهُ لِي وَأَنَا أَجْزِي بِهِ، وَالصِّيَامُ جُنَّةٌ؛ وَإِذَا كَانَ يَوْمُ صَوْمِ أَحَدِكُمْ فَلَا يَرْفُثْ، وَلَا يَصْخَبْ، وَإِنْ سَابَّهُ أَحَدٌ أَوْ قَاتَلَهُ فَلْيَقُلْ: إِنِّي امْرُؤٌ صَائِمٌ، وَالذي نَفْسُ مُحَمَّدٍ بِيَدِهِ لَخَلُوفُ فَمِ الصَّائِمِ عِنْدَ اللّٰهِ أَطْيَبُ مِنْ رِيحِ المِسْكِ، وَلِلصَّائِمِ فَرْحَتَانِ يَفْرَحُهُمَا: إِذَا أَفْطَرَ فَرِحَ بِفِطْرِهِ، وَإِذَا لَقِيَ رَبَّهُ فَرِحَ بِصَوْمِهِ

«Бөек Аллаһ [болай дип] әйтте: «Адәм баласының уразадан кала барлык гамәлләре аның үзенә, ул ( ураза) – Минем өчен һәм Мин аның өчен әҗер-савап бирермен; ураза гөнаһлардан калкан булып тора; әгәр берәрегез ураза тотса начар сүзләр әйтмәсен, ачуланмасын һәм кычкырмасын; әгәр аның белән берәрсе сугыша башласа яки аны сүксә, ул: «Чынлыкта,мин ураза тотам!»,– дип әйтсен. Һәм Мөхәммәднең җанына хуҗа булган Аллаһ белән ант итәм – ураза тотучының авызыннан чыккан ис Аллаһ өчен мускус исеннән дә ямьлерәк! Ураза тотучы ике нәрсәгә сөенә: ураза тотып авыз ачканда һәм үз Раббысы белән очрашканда».

«Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 4328.

557 — Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр ителә:

رَمَضَانُ شَهْرٌ مُبَارَكٌ فِيهِ تُفْتَحُ أَبْوَابُ الجَنَّةِ، وَتُغْلَقُ فِيهِ أَبْوَابُ السَّعِيرِ، وَتُصَفَّدُ فِيهِ الشَّياطِينُ وَيُنَادِي مُنَادٍ كُلَّ لَيْلَةٍ: يَا بَاغِيَ الشَّرِّ أَقْصِرْ

«Рамазан –бәрәкәтле ай, Рамазан ае килгәч Җәннәт ишекләре ачыла, Җәһәннәм ишекләре ябыла һәм шәйтаннарга чылбырдан богау кидерелә һәм һәртөнне күктән Өндәүче: "Изгелеккә омтылган кеше, бар (яхшы гамәлләр кыл); явызлык теләгән кеше, тукта!",- дип әйтер».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 3519.

539— Пәйгамбәребездән ﷺ хәбәр ителә:

مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

«Кем рамазан аенда Аллаһның әҗеренә өмет итеп ураза тота икән, аның алдагы барлык гөнаһлары да кичереләчәк».

📚 «Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагъир», 6326.